**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Беловка авыл җирлеге Советы**
**Карар**

« 20 » ноябрь 2017 ел № 45

## Җир салымы турында

**1 нче маддә. Гомуми нигезләмәләр**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, әлеге карар белән Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә түләргә мәҗбүри булган җир салымы (алга таба – салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 нче маддә. Салым ставкалары

Салым ставкалары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалану зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җир участокларына карата 0,3% ;

2) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокук өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;

3) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, бакчачылык яки терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,1% ;

4) автономияле учреждениеләрнең җир участокларына; Татарстан Республикасы бюджетыннан, Аксубай муниципаль районы бюджетыннан һәм җирлек бюджетыннан финанслана торган бюджет учреждениеләренә, казна учреждениеләренә карата 0,01% ;

5) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%.

3 нче маддә. Салым ташламалары

Салымнан азат ителәләр:

оешмалар, учреждениеләр гражданнар җирләүләре белән шөгыльләнүче җир участокларына карата.

1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 2 статьяның 5 пунктында билгеләнгән 1/30 күләмендә салым ташламасы (0,05 %) билгеләргә.

4 нче маддә. Хисап чоры

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары булып календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

5 нче маддә. Салым түләү тәртибе һәм вакыты

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше буенча тиешле салым ставкасының 1/4 өлеше күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла. Беренче квартал тәмамланганнан соң аванс түләүләрен түләү вакыты 10 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал тәмамланганнан соң 10 августтан да соңга калмыйча һәм өченче квартал тәмамланганнан соң, 10 ноябрьдән дә соңга калмыйча.

Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы салым чоры тәмамланганнан соң киләсе елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

6 нчы маддә. Бу карарның үз көченә керүе

Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма район газетасында рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер айдан да иртәрәк түгел һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыгарга тиеш

Әлеге карар үз көченә кергән көннән башлап 2008 елның 27 октябрендәге 12 номерлы «җир салымы турында» карарны үз көчен югалткан дип танырга (2009 елның 23 июнендәге 11 номерлы, 2009 елның 20 ноябрендәге 21 номерлы, 2010 елның 26 октябрендәге 4 номерлы, 2014 елның 11 ноябрендәге 15 номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 8 номерлы үзгәрешләр белән).

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: И.Р.Махмутов